Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Чури-Бураш авыл жирлеге башкарма комитетының 2022 елның 1 февраленендәге 3 номерлы «Чури-Бураш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында»карары

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 27 гыйнварындагы «2022 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициенты күләмен раслау турында» 57 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Чури-Бураш авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. 2022 елның 1 февраленнән күмү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен, әлеге карарга 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә, Чури-Бураш авыл җирлегендә 6964,68 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда, хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен үзем тикшереп торам.

Чури-Бураш авыл
җирлеге башлыгы И.Р.Мифтахов

1 нче кушымта

Чури-Бураш авыл җирлегендә 2022 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе *( сум.)* |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| Мәетне төрү | 2104,09 |
| 3. Табут һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны китереп бирү | 970,50 |
| 4. Мәетне (җәсәдләрен) зиратка илтү | 1009,48 |
| 5. Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 2880,61 |
| Барлыгы | 6964,68 |

2 нче кушымта

Чури-Бураш авыл җирлегендә 2022 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе ( сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2.Табут һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны китереп бирү | 2656,34 |
| 3. Мәетне (җәсәдләрен) зиратка илтү | 1154,24 |
| 4. Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 3154,10 |
| Барлыгы | 6964,68 |